СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.08.2026 г. Заинск № 67

**Зәй муниципаль районы Советының 2025 елның 8 декабрендәге 18 номерлы «2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Зәй муниципаль районы бюджеты турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы белән Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Советының 2025 елның 8 декабрендәге 18 номерлы «2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Зәй муниципаль районы бюджеты турында» карарына (16.04.2026 № 39, 10.06.2026 № 51 үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 1 пунктында:

а) 1 өлештә «2878362,4» саннарын «2941379,2» саннарына алмаштырырга;

б) 2 өлештә «2969536,2» саннарын «3032553,0» саннарына алмаштырырга.

1.2. 6 статьяда «4872,0» саннарын «4828,6» саннарына алмаштырырга;

1.3. «2026 елга Зәй муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 нче кушымтаның 1 нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә;

1.4. «2025 елга Зәй муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәре» 2 нче кушымтаның 1 нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә редакциягә бәян итәргә;

1.5. «2026 елга Зәй муниципаль районы бюджеты чыгымнарынын ведомство структурасы» 3 нче кушымтаның 1 нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә;

1.6. «Зәй муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2026 елга бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» 4 нче кушымтаның 1 нче таблицасына әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә һәм редакциядә бәян итәргә;

1.7. «2026 елга җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр» 5 нче кушымтаның 1 нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә редакциягә бәян итәргә.

1.6. «2026 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар» 7 нче кушымтаның 1 нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә редакциягә бәян итәргә;

1.7. «2026 елга җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бүлү (Татарстан Республикасы резерв фонды һәм Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының Резерв фонды акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы бюджетыннан керә торган бюджетара трансфертларны искәртеп» 10 нчы кушымта өстәргә һәм әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат» порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет Рәисе** **Р. Г. Кәримов**